**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г. Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2024 елның 5 августы** **59-РС номер**

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмә хакында» Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 5 декабрендәге 95-РС номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78_4 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2024елның 22 июнендәге 154-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмә хакында» 2022 елның 5 декабрендәге 95-РС номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

15.1 пунктының 6 абзацында «әлеге статьяның 1 пунктындагы 2 һәм 3 пунктчаларында каралган субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары лимитларының бюджет акчаларын алучыга җиткерелгән гаиәлдә булу срогыннан артыграк булырга мөмкин» сүзләрен «Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә башка срок билгеләнмәгән булса» сүзләренә алмаштырырга;

Әлеге пунктта каралган килешүләр "Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында" 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә башка срок билгеләнмәгән булса, социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүләргә муниципаль социаль заказда күрсәтелгән социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтү срогына төзелә".

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**